СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре № 255

«Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 5 февралендәге, 124 номерлы карарына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. «Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 94 номерлы карарына (2022 елның 11 апрелендәге 111 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 190 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәдә:

1.7. пунктының 1) һәм 2) пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) планлаштыру структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки бакчачылык алып бару территориясе;

2) урам-юл челтәре элементы - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында bavly.tatar.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров